МИНИСТЕРСТВО
ЗДРАВООХРАНЕНИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.03.2019 г. Казань № 560

Татарстан Республикасында балаларга
өйдә үпкәләрнең озакка сузылган ясалма
вентиляциясен үткәрүне оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 3 августыннан №635 «Паллиатив медицина ярдәмен үстерү максатларында 2018 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлардан файдалану Тәртибен раслау турында» Карарын, РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының 2015 елның 14 апреленнән № 193н «Балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтү Тәртибен раслау турында» боерыгын (2018 елның 28 июненнән №401н үзгәрешләре белән) үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасында балаларга паллиатив медицина ярдәмен үстерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Махсус медицина җиһазларын (үпкәләрне ясалма вентиляцияләү өчен аппаратны, кислород концентраторын, йөткерткеч аппаратын) кулланып, балаларга паллиатив медицина ярдәмен амбулатор шартларда (өйдә) күрсәтү оештыруны гамәлгә ашыручы медицина оешмаларының Исемлеген (№1 Кушымта);

Өйдә үпкәләрнең озакка сузылган ясалма вентиляциясен үткәрү буенча чаралар оештыруның Вакытлы тәртибен (№ 2 Кушымта);

Медицина җиһазларын өйдә түләүсез вакытлы файдалануга тапшыру турында килешүнең тәкъдим ителгән формасын (№3 Кушымта) (алга таба – килешү);

2. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» ДАССУнең (А.И.Зиатдинов), Яр Чаллы шәһ. «Кама балалар медицина үзәге» ДАССУнең (Т. Ф. Мөбәрәкшин), Түбән Кама шәһ. «Перинатальүзәк белән Балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУнең (Р. А. Хәмидуллин) баш табибларына түбәндегеләрне оештыруны тәэмин итәргә:

2.1. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2015 елның 14 апреленнән № 193н боерыгы (алга таба – Балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтү Тәртибе) белән расланган Балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтү Тәртибенә туры китереп, махсус медицина җиһазларын (үпкәләрне ясалма вентиляцияләү өчен аппаратны, кислород концентраторын, йөткерткеч аппаратын) куллану белән, Татарстан Республикасы балаларына паллиатив медицина ярдәмен амбулатор шартларда (өйдә) күрсәтүне;

2.2. әлеге боерыкка туры китереп өйдә паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә пациентны карауны турыдан-туры гамәлгә ашыручы затка медицина оешмасы тарафыннан махсус медицина җиһазларын (үпкәләрне ясалма вентиляцияләү аппаратын, кислород концентраторын, йөткерткеч аппаратын) һәм кирәкле чыгым материалларын тапшыруны;

2.3. балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештырганда табибларның башка медицина оешмаларының белгечләре белән үзара хезмәттәшлеген;

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының балаларга паллиатив ярдәм буенча баш штаттан тыш белгеченә (Н.А.Гиниятова) Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче медицина оешмалары табибларына балаларга паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыруның мәсьәләләре буенча оештыру-методик ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары С.А.Осиповка йөкләргә.

Министр М.Н. Садыйков

_______________ № _______

ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
№ 1 Кушымта

Махсус медицина җиһазларын
(үпкәләрне ясалма вентиляцияләү өчен аппаратны, кислород концентраторын, йөткерткеч аппаратын) куллану белән, балаларга паллиатив медицина ярдәмен амбулатор шартларда (өйдә) күрсәтүне оештыруны гамәлгә ашыручы медицина оешмаларының Исемлеге

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» ДАССУ;
«Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ (Яр Чаллы шәһ.);
«Перинаталь үзәк белән Балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ (Түбән Кама шәһ.);

«Лениногорск үзәк район хастаханәсе» ДАССУнең Балалар хастаханәсе.

_______________ № _______

ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгына
№ 2 Кушымта

Өйдә үпкәләрнең озакка сузылган ясалма вентиляциясен үткәрү буенча чаралар оештыруның Вакытлы тәртибе

1. Әлеге Вакытлы тәртип баларга паллиатив медицина ярдәме күрсәткәндә өй шартларында үпкәләрнең озакка сузылган ясалма вентиляциясен (алга таба – ҮЯВ) оештыру буенча чаралар үткәрү кагыйдәләрен билгели.

2. Пациентка ҮЯВен өй шартларында үткәрүгә күрсәтмәләрен табиблар комиссиясе билгели. Аның составы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2012 елның 5 маеннан № 502н «Медицина оешмасының табиб комиссиясен төзү һәм эшчәнлек тәртибен раслау турында» боерыгына туры китереп төзелә һәм дәвалаучы табибны, табибны-анестезиологны-реаниматологны, паллиатив медицина ярдәме табибын үз эченә кертә.

3. Өйдә ҮЯВен үткәрүгә әзерләү өчен пациентны паллиатив ярдәм бүлегенә (паллиатив медицина ярдәме койкасына) урнаштыруның (күчерүнең) мәҗбүри шартлары булып түбәндәгеләр тора:

пациентның (законлы вәкиленең) һәм (яисә) турыдан-туры пациентны карауны гамәлгә ашыручы затларның өйдә ҮЯВ үткәрелгәндә аны карауны гамәлгә ашыруга кушып бирелә торган форма буенча гаризасы (әлеге Тәртипкә № 1 Кушымта);

өйдә үпкәләрнең ясалма вентиляциясен үткәрүгә пациентның (законлы вәкилнең) кушып бирелә торган форма буенча хәбәр ителгән ирекле ризалыгы (әлеге Тәртипкә № 2 Кушымта); әгәр пациентның хәле үз ихтыярын белдерергә мөмкинлек бирмәсә яисә законлы вәкилләре булмаса – 2011 елның 21 ноябреннән №323-ФЗ «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законында каралган очракларда табиблар консилиумы;

ашыгыч хәлләр очрагында медицина оешмаларының ирешерлеге (тәүлек буе телефон элемтәсе, килү вакыты 20 минуттан да артмаска тиеш);

кушымта итеп бирелә торган формасы буенча пациентка өйдә ҮЯВ үткәрү өчен өй шартларының куркынычсызлыгы турында паллиатив медицина ярдәме табибы, табиб-анестезиолог-реаниматолог, психолог,

куркынычсызлык техникасы буенча инженер составында комиссия бәяләмәсе (әлеге Тәртипкә № 3 Кушымта).

4. Өйдә ҮЯВ үткәрү өчен стационардан чыгару өчен мәҗбүри шартлар:

1) пациентның (законлы вәкиленең) стационар шартларда дәвалаудан язма рәвешендә баш тартуы;

2) өй шартларында озакка сузылган ҮЯВ үткәрү өчен кирәкле медицина җиһазларының булуы;

3)ҮЯВдә булучы затны карау принципларына пациентны карауны үтәүче зат тарафыннан укытуны узу, әлеге Тәртипкә туры китереп;

4) пациентның тотрыклы хале;

5) өйдә озак вакытлар ҮЯВдә булучы пациент яшәячәк территориягә хезмәт күрсәтә торган балаларга паллиатив медицина ярдәменең күчмә патронаж хезмәте булуы һәм өстәмә җиһазландыруда:
- редукторлы кислород баллоны;
- генератор;
- респиратор интерфейслар булуы.

5. Өйдә ҮЯВ үткәрүгә әзерлекне гамәлгә ашыручы медицина оешмасында табиб-анестезиолог-реаниматолог:

медицина оешмасының җитәкчесе тарафыннан расланган укыту планына туры китереп, ҮЯВдә булучы пациентны карау принципларына турыдан-туры карый торган затларның укытуын уздыра. Ул тәмамлангач, ҮЯВдә булучы пациентны карауны турыдан-туры гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан үзләштерелгән компетенцияләр исемлегенә имза куела, кушып бирелә торган форма буенча (әлеге Тәртипкә № 4 Кушымта).

пациентка өйдә ҮЯВен үткәрү өчен медицина җиһазларын һәм ҮЯВ параметрларын сайлауны гамәлгә ашыра.

6. Өй шартларында ҮЯВ үткәрүгә әзерлекне гамәлгә ашыручы медицина оешмасы, пациентны өй шартларында ҮЯВнә күчерү вакытында, бу хакта яшәү урыны буенча медицина оешмаларына хәбәр итә: ашыгыч медицина ярдәме станциясенә (медицина оешмасының ашыгыч медицина ярдәме бүлегенә), сырхауханәсенә (медицина оешмасының сырхауханә бүлегенә), (анестезиология–реанимация) реанимация һәм интенсив терапия бүлегенә ия булучы якын территориаль ирешлелектәге стационарга.

7. Медицина оешмалары тарафыннан («Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» ДАССУ, «Кама балалар медицина үзәге» ДАССУ (Яр Чаллы шәһ.), «Перинаталь узәк белән Балалар шәһәр хастаханәсе» ДАССУ (Түбән Кама шәһ.) махсус медицина җиһазларын (үпкәләрнең ясалма вентиляциясе өчен аппаратны, кислород концентраторын, йөткерткеч аппаратын) һәм кирәкле чыгым материалларын өйдә ҮЯВен үткәргәндә пациентны карауны

турыдан-туры гамәлгә ашыручы затка тапшыру, медицина җиһазларын өйдә түләүсез вакытлы файдалануга тапшыру турындагы килешү һәм медицина җиһазларын кабул итү-тапшыру акты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Медицина оешмасының күрсәтелгән затлары тарафыннан җиһазларны кире кайтару медицина җиһазларын кире кайтару акты буенча башкарыла.

8. Пациентны медицина оешмасыннан өйгә медицина эвакуацияләве шуннан соңгы өендәге ҮЯВ өчен медицина оешмасының табибы-анестезиологы-реаниматологы озатуында «В» яки «С» класслы медицина транспортыннан файдаланып гамәлгә ашырыла. Гражданин яшәү урыны буенча ашыгыч медицина ярдәме станциясенең (медицина оешмасының ашыгыч медицина ярдәме бүлегенең) «В» яисә «С» класслы медицина транспортыннан файдалану рөхсәт ителә.

9. Беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының җитәкчеләре, пациентны ҮЯВсе алу өчен өй шартларына күчерү турында мәгълүмат алгач өй шартларында ҮЯВен алучы пациентны стационарга күчерүне таләп итә торган хәлләр барлыкка килгәндә чараларның исемлеген һәм эзлеклелеген медицина оешмасы буенча боерык тарафыннан билгелиләр һәм күрсәтелгән чараларны үтәү өчен җаваплы затны билгелиләр.

10. Өй шартларында ҮЯВсе булган пациентка түбәндәге күзәтү тәэмин ителә:

паллиатив медицина ярдәменең күчмә патронаж хезмәте белгечләре тарафыннан (планлы күзәтү айга ике тапкырдан да ким түгел);

гражданинның яшәү урыны буенча медицина оешмасы боерыгы белән билгеләнгән табиб-анестезиолог-реаниматолог һәм медицина оешмасының җаваплы заты тарафыннан (планлы күзәтү айга бер тапкырдан да ким булмаска тиеш, клиник шартларга бәйле);

өйдә ҮЯВ үткәрүгә әзерлекне гамәлгә ашыручы медицина оешмасының табибы-анестезиологы-реаниматологы тарафыннан (өч айга бер тапкырдан да ким булмаган планлы күзәтү).

Өйдә үпкәләрнең озакка сузылган
ясалма вентиляциясен үткәрү буенча
чаралар оештыруның Вакытлы тәртибенә
№1 Кушымта

Форма

______________________________________
медицина оешмасының исеме

баш табибы

______________________________________
медицина оешмасы баш табибы фамилиясе, исеме, атасының исеме

Гариза

Пациентны ______________________________________________
фамилиясе, исеме, атасының исеме

туган көне:__________

өй шартларында махсус медицина җиһазларын (үпкәләрне ясалма вентиляцияләү өчен аппаратны, кислород концентраторын, йөткерткеч аппаратын) кулланып өйдә паллиатив медицина ярдәме –үпкәләрнең ясалма вентиляциясен (ҮЯВ) алу өчен ____________________________ адресы буенча күчерергә.

Күрсәтелгән адрес буенча бина милекчесе медицина җиһазларын куллану белән ҮЯВ үткәрү өчен күрсәтелгән адрес буенча өй шартларының куркынычсызлыгын бәяләүгә риза.

Пациентны карауны гамәлгә ашыручы затлар ҮЯВдә булучы пациентны карау принципларын өйрәнүгә риза.

Пациент (законлы вәкил)

________________/_____________________________________дата:________________
имза имзаның расшифровкасы

Бина милекчесе

________________/_____________________________________дата:________________
имза имзаның расшифровкасы

Өйдә ҮЯВдә булучы пациентны карауны үтәүче затлар

______________________________________________________________________
имза, фамилия, исем, атасының исеме

Паспорт: ________________ ________________________ бирелгән:
сериясе, номеры биргән орган

Бирү датасы: _____________ Контакт телефоны: __________________

________________/__________________________________________дата:__________
имза имзаның расшифровкасы

Өйдә үпкәләрнең озакка сузылган
ясалма вентиляциясен үткәрү буенча
чаралар оештыруның Вакытлы тәртибенә
№2 Кушымта

Форма

Өйдә үпкәләрнең ясалма вентиляциясен үткәрүгә
хәбәр ителгән ирекле ризалык

Мин,
_______________________________________________________________________________
пациентның Ф.И.О.

_____елның «__»_____________ туган, ________________________ Законлы вәкил йөзендә
_____________________________________________________________ нигезендә эш итүче,
нигез документы

___________________________________________ адресы буенча теркәлгән
өйдәге үпкәләрнең ясалма вентиляциясен дәвам итү өчен медицина оешмасыннан(стационардан) күчерү мөмкинлеге белән таныштырылдым.

Өйдә үпкәләрнең ясалма вентиляциясен үткәрүне дәвам итү өчен мине медицина оешмасыннан (стационардан) күчерү өчен хәбәр ителгән ирекле ризалык бирәм.

Медицина хезмәткәре ____________________________
_______________________________________________________________________________
медицина хезмәткәренең вазыйфасы, Ф. И. О.
тарафыннан минем өчен уңайлы формада өйдә үпкәләрнең ясалма вентиляциясен һәм медицина хезмәткәрләре, шул санда табиб анестезиолог-реаниматолог белән күзәтү ничек тормышка ашыралачак аңлатылды, дип раслыйм.

Мин өзлегүләр үсешенең мөмкин рисклары белән, шул санда үпкәләрнең ясалма вентиляциясе өчен медицина җиһазларын кулланугa бәйле рисклары белән, таныштым.

Миңа өйдәге үпкәләрнең ясалма вентиляциясен дәвам итү өчен яшәү урыны буенча медицина оешмасыннан күчерүдән баш тарту хокукым булуы аңлатылды.

Минем сәламәтлегемнең торышы яки мин законлы вәкиле булган затның хәле турында мәгълүмат тапшырылырга мөмкин булган мин сайлаган затлар турында мәгълүматлар (кирәкмәгәнне сызырга):
_______________________________________________________________________________
гражданинның Ф.И.О., контакт телефоны
_______________________________________________________________________________
гражданинның Ф.И.О., контакт телефоны

Пациент (Законлы вәкил)__________/_______________________________/____________
имза пациентның (Законлы вәкиленең) Ф.И.О. дата

Медицина хезмәткәре
_____________/_____________/ ____________________________________/ ____________
вазыйфасы имзасы Медицина хезмәткәренең Ф.И.О. дата

Өйдә үпкәләрнең озакка сузылган
ясалма вентиляциясен үткәрү буенча
чаралар оештыруның вакытлы тәртибенә
№3 Кушымта

## Өйдә ҮЯВ үткәрү өчен өй шартларының куркынычсызлыгын бәяләү буенча комиссия нәтиҗәсе

Пациентның фамилиясе, исеме, атасының исеме____________________________________________

Яше________________________________________________________________________

Фактик йорт адресы__________________________________________________________

Теркәү буенча йорт адресы____________________________________________________

Иминият полисының номеры___________________________________________________

Пациентның яшәү урыны гыйбарәт:

☐Йорт

☐Фатир

☐Башка (нәрсә)

Өйдә стационар телефонның булуы

☐Әйе ☐Юк

Өйгә кергәндә домофонның булуы

☐Әйе ☐Юк

Кичектергесез коткару хезмәте өчен торакның үтемлелеге

☐Әйе ☐Юк

Яшәү урыны буенча хастаханәләр исемлеге:

1.__________________________________________________________________________

2.__________________________________________________________________________

3.__________________________________________________________________________

Кислород җиһазларын кулланунның куркынычсызлыгы:

Бинада «Тәмәке тарту тыела» билгесе урнаштырылган

☐Әйе ☐Юк

Бинада тәмәке тарталармы:

☐Әйе ☐Юк

Кислород җиһазларын саклау урыны һәм тәртибе куркынычсызлык таләпләренә туры килә

☐Әйе ☐Юк

Энергия белән тәэмин итү:

Өйдә электр белән тәэмин итү бар

☐Әйе ☐Юк

Электр розеткалары җиргә тоташтырылган

☐Әйе ☐Юк ☐Мәгълүматлар юк

Өй шартларында медицина җиһазларын куллану өчен техник таләпләргә туры килә торган удлинительләр кулланыла

☐Әйе ☐Юк ☐Мәгълүматлар юк

Өй шартларында медицина җиһазларын куллану өчен электр челтәрендә көчәнеш җитәрлек

☐Әйе ☐Юк ☐Мәгълүматлар юк

Өзлексез электр белән тәэмин итү чыганагының булуы

☐Әйе ☐Юк

Янгын куркынычы:

Янгын сүндергечләрнең булуы

☐Әйе ☐Юк

Янгын сүндергечләр төзек хәлдә

☐Әйе ☐Юк

Соңгы 30 көн эчендә янгын сүндергечләр тикшерелгән иделәр

☐Әйе ☐Юк

Гаиләгә янгын сүндергеч сатып алырга киңәш ителде һәм
аны кайда сатып алырга булуы хәбәр ителде

☐Әйе ☐Юк

Экологик таләпләр:

Медицина җиһазларына якын килү уңайлы һәм адекват

☐Әйе ☐Юк ☐Мәгълүматлар юк

Ишекнең зурлыгы ҮЯВ өчен җиһазны тоткарлыксыз алып керергә мөмкинлек бирә

☐Әйе ☐Юк ☐Мәгълүматлар юк

Өйдә бөҗәкләр һәм/яки кимерүчеләр юк

☐Әйе ☐Бар

Йорт медицина җиһазын куркынычсыз куллану өчен киртәләр юк

☐Әйе ☐Юк ☐Мәгълүматлар юк

Өй буенча имин хәрәкәт итү өчен киртәләр юк

☐Әйе ☐Бар

Суыткыч/суыткыч камера техник яктан төзек

☐Әйе ☐Юк

Үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү тиешле хәлдә

☐Әйе ☐Юк

Өйне җылыту системасы гыйбарәт:

☐үзәкләштерелгән җылыту системасы

☐үзәкләштерелмәгән җылыту системасы

(аныклау)______________________________________________________________________________

Өйдә һаваны кондиционерлау һәм суыту системалары бар

☐Әйе ☐Юк

Өйнең һаваны кондиционерлау һәм суыту системалары гыйбарәт:

- кондиционер
- сплит-системасы
- һаваны дымландыру системасы
- башка (нәрсә)_______________________________________________________________________

Өйнең һаваны кондиционерлау һәм суыту системалары түләнелгән һөнәри техник хезмәт күрсәтүдә торалар:

☐Әйе ☐Юк

Йорт хайваннары (төре, саны)

☐Әйе ☐Юк

Медицина кирәк-яракларын һәм очлы предметларны саклау һәм утильләштерү өчен шартлар бар

☐Әйе ☐Юк ☐Мәгълүматлар юк

Карауны гамәлгә ашыручы затлар көнкүреш шартларын бәяләгәндә билгеләнгән барлык мөмкин булган хәвеф-хәтәрләр һәм куркынычлыклар турында мәгълүмат алдылар.

☐Әйе ☐Юк ☐Мәгълүматлар юк

Пациентның өй шартлары куркынычсызлыгының дәрәҗәсен күтәрү буенча киңәшләр:

1.________________________________________

2.________________________________________

3.________________________________________

4.________________________________________

Карауны гамәлгә ашыручы затлар куркынычсызлык проблемалары һәм пациентның куркынычсызлыгын яхшырту буенча киңәшләр аларга аңлаешлы булуын раслыйлар:

☐Әйе ☐Юк

Алдагы гамәлләр планы:

1.________________________________________

2.________________________________________

3.________________________________________

4.________________________________________

Комиссия нәтиҗәсе:

________________________________________

________________________________________

Паллиатив медицина ярдәме табибы: ______________/______________ дата:________
имза имзаның расшифровкасы

Табиб-анестезиолог-реаниматолог ______________/______________ дата:________
имза имзаның расшифровкасы

Психолог ______________/______________ дата:________
имза имзаның расшифровкасы

Пациент (Законлы вәкиле) ______________/______________ дата:________
имза имзаның расшифровкасы

Өйдә ҮЯВдә булган пациент артыннан карап торуны гамәлгә ашыручы затлар

______________/____________________ дата:______________
имза имзаның расшифровкасы

______________/____________________ дата:______________
имза имзаның расшифровкасы

Өйдә үпкәләрнең озакка сузылган
ясалма вентиляциясен үткәрү буенча
чаралар оештыруның вакытлы тәртибенә
№4 Кушымта

Йорт шартларында озак вакытка сузылган ҮЯВдә булган пациентны турыдан-туры карауны гамәлгә ашырачак затлар тарафыннан үзләштерелгән компетенцияләр Исемлеге

1. Трахеобронхиаль агач санациясе.

2. Назогастраль зонд кертү (алга таба – НГЗ), НГЗ аша ашату

3. Гастростоманы алыштыру, гастростома артыннан карау, гастростом аша ашату буенча гамәли күнекмәләр.

4. Трахеостомик канюляны алыштыру, трахеостома артыннан карау буенча гамәли күнекмәләр.

5. Кул ярдәмендәҮЯВ үткәрүне белү.

6. ҮЯВ аппаратын көйләү, эксплуатацияләү, төзеклеген тикшерү, агымдагы кимчелекләрен бетерү буенча күнекмәләр.

7. Пациент хәленең параметрлары: сулыш ешлыгы, пульс ешлыгы, тире капламының төсләре, күкрәк читлеге экскурсияләре, тирләве, йокычанлыгы, тән температурасы нигезендә ҮЯВ адекватлыгын бәяләү.

8. Түбәндәге ҮЯВ параметрларын урнаштыра белү: ҮЯВ аппараты контурында агымны; мәҗбүри сулыш алуларның ешлыгын; сулыш алуның иң югары басымнарын; сулыш чыгару ахырында уңай басымны; сулыш алуның күләмнәрен; пульслы оксиметр тикшерү астында кислород концентрациясен; дымландыргыч температурасын яки җылыны һәм дымлылыкны саклаучы фильтрны урнаштыра һәм алыштыра белү.

9. Кризислы кичектергесез хәлләргә адекват реакция ясау: электр белән тәэмин итүнең өзеклеге; очраклы деканюляция; трахеостомик канюлянең обтурациясе; ҮЯВ аппараты ватылу; пациентның хәле начарлану.

10. Йогышлы иминлекне тәэмин итү буенча гигиена процедураларын һәм чараларны үтәү.

11. Түбәндәге ярдәмчел җайланмалардан файдалана белү: кислород концентраторы, электроаспиратор, пульсоксиметр, йөткерткеч аппараты, дымландыргыч.

12. Чыгым материалларын куллану кагыйдәләрен белү (алыштыруның ешлыгы, утильләштерү кагыйдәләре, минималь рөхсәт ителгән калган материал).

13. Балалар өчен алгоритм буенча йөрәк-үпкә реанимациясе буенча чараларның төп комплексын булдыра алу.

Пациент (Законлы вәкиле)

| ______________________________ | __________ | __________ |
| --- | --- | --- |
| фамилия, исем, атасының исеме | имза | дата |

Пациентны турыдан-туры карауны гамәлгә ашырачак затлар:

| ______________________________ | __________ | __________ |
| --- | --- | --- |
| фамилия, исем, атасының исеме | имза | дата |
| ______________________________ | __________ | __________ |
| фамилия, исем, атасының исеме | имза | дата |

Йорт шартларында озак вакытка сузылган ҮЯВдә булган гражданинны карау буенча укыту үткәргән табиб-анестезиолог-реаниматолог:

| ______________________________ | __________ | __________ |
| --- | --- | --- |
| фамилия, исем, атасының исеме тулысынча | имза | дата |

_______________ № ______

ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгының боерыгына
№3 Кушымта

Киңәш ителгән форма

**Өйдә медицина җиһазын**
**түләүсез вакытлы куллануга тапшыру турында**
**Килешү**

______________________ 20___ел. «______» ______________

төзү урыны

Бер яктан, устав нигезендә гамәлдә булучы, алга таба «Медицина оешмасы» дип аталучы, ______________________________________________________________________,

медицина оешмасының атамасы

баш табиб йөзендә _______________________________________________________ ,

һәм икенче яктан алга таба «Гражданин» дип аталучы ______________________________

махсус медицина җиһазын куллану белән өйдә паллиатив

______________________________________________________________________

медицина ярдәмен күрсәтүгә мохтаҗ булган пациентны турыдан-туры карауны гамәлгә ашырачак затларның (затның) фамилиясе,

______________________________________________________________________,

исеме, атасының исеме

бергә «Яклар» дип аталучы, түбәндәге турында әлеге Килешүне төзеделәр (алга таба Килешү):

**1. Килешү предметы, Төп нигезләмәләр.**

1.1. Килешү предметы булып махсус медицина җиһазын куллану белән Пациентка______________________________________________________________
______________________________________________________________________

(фамилия, исем, атасының исеме, туу датасы )

______________________________________________________________адресы
______________________________________________________________________

буенча өйдә паллиатив медицина ярдәме күрсәтү буенча Якларның үзара хезмәттәшлеге булып тора.

1.2. Әлеге Килешүнең №1 Кушымтасында күрсәтелгән махсус медицина җиһазын һәм аның белән файдалану өчен кирәк булган медицина билгеләнешендәге предметларны (алга таба – Җиһаз) Медицина оешмасы бирә, ә гражданин түләүсез вакытлыча куллануга кабул итә һәм Җиһазны, нормаль тузуны исәпкә алып, кабул иткәндәге халәтендә кире кайтаруга вәгъдә бирә.

1.3.Әлеге Килешү буенча тапшырыла торган җиһаз Медицина оешмасы карамагында тора.

1.4.Килешү буенча Җиһаз белән түләүсез файдалану срогы___________________________
______________________________________________________________________

1.5.Җиһаз Килешүнең1.1 пунктында күрсәтелгән адрес буенча гына кулланыла.

1.6. Җиһаз Медицина оешмасы тарафыннан Гражданинга әлеге Килешүгә кул куелган көннән 2 (ике) эш көне эчендә Җиһазга кагыла торган барлык техник паспортларының, файдалану буенча инструкция күчермәләре белән Җиһазны Кабул итү-тапшыру акты (әлеге Килешүгә №2 Кушымта) буенча тапшырыла.

1.7. Җиһазны Кабул итү-тапшыру актына Яклар тарафыннан кул кую вакытыннан башлап Җиһазның ватылу яки аңа зыян килү куркынычы Гражданинга күчә.

**2.Якларның хокуклары һәм бурычлары**

2.1. Медицина оешмасы:

2.1.1. Гражданинга Җиһазны түләүсез вакытлыча файдалануга тапшырганчы аның Җиһаз белән куллану кагыйдәләренә өйрәтүне тәэмин итә.

2.1.2. Кабул итү-тапшыру акты буенча комплектлы итеп Җиһазны төзек хәлдә тапшыра.

2.1.3.Җиһазны Кабул итү-тапшыру актына Яклар тарафыннан кул кую вакытыннан башлап 1 көн эчендә Җиһазның эшләтеп җибәрү-көйләү эшләрен башкара.

2.1.4. Җиһаздан куллануны контрольдә тота. Җиһазны нәтиҗәсез яки максатсыз файдалану ачыкланган очракта, Медицина оешмасы Гражданинга язма кисәтү җибәрә. Җиһазны нәтиҗәсез яки максатсыз файдалану буенча кабат ачыкланган очракта, Гражданинга Килешүне вакытыннан алда өзү һәм Җиһазны кире кайтару турында язма белдерү кәгазе җибәрелә.

2.1.5.Гражданин тарафыннан Җиһазны кайтарганда Медицина оешмасы Гражданин катнашында Җиһазга техник карап тикшерү, аның комплектлылыгын тикшерү үткәрә, бу хакта Җиһазны Кире кайтару акты төзелә (әлеге Килешүгә №3 Кушымта).

2.1.6.Медицина оешмасы җитештерүче тарафыннан билгеләнгән срокларда Җиһазга сервис хезмәте күрсәтә, шулай ук Гражданин запросы буенча Җиһазның халәтен тикшерә.

2.2. Гражданин:

2.2.1. Медицина оешмасының вәкаләтле хезмәткәрләренә Җиһазны урнаштыру, җибәрү-көйләү эшләрен үткәрү, сервис хезмәте күрсәтү, Җиһазның халәтен тикшерү өчен, шулай ук Җиһазның халәте, аның максатчан һәм нәтиҗәле кулланылышын контрольдә тоту Кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) туры китереп Җиһазны куллануны контрольдә тоту өчен бинага тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итә (әлеге Килешүгә №4 Кушымта).

2.2.2. Җиһазны залогка бирергә, Җиһазны өченче затларга, шул исәптән арендага, бушлай файдалануга тапшырырга хокуклы түгел.

2.2.3. Әлеге Килешү буенча үз хокукларын һәм бурычларын өченче затларга тапшырырга хокуклы түгел.

2.2.4. Куллану срогы чыкканчы Җиһазны Медицина оешмасына кире кайтару Акты буенча кире кайтарырга хокуклы (Килешүнең1.4 пункты). Җиһазны вакытыннан алда кайтару турында Медицина оешмасына Җиһазны кире кайтару турында язмача белдерү кәгазе җибәрелә.

2.2.5. Җиһаздан бары тик аның билгеләнеше буенча һәм әлеге Килешү шартлары нигезендә генә файдалануны тәэмин итә.

2.2.6. Медицина оешмасының язмача рөхсәтеннән башка Җиһазның аергысыз яхшыртуын эшләргә хокуклы түгел.

2.2.7. Җиһазны төзек хәлдә булуын тәэмин итә. Җиһазның эшендә техник проблемалар туганда Гражданин бу хакта Медицина оешмасы хезмәткәрләренә хәбәр итәргә тиеш.

2.2.8. Җиһазны Медицина оешмасына тиешле халәттә, төзек хәлдә, Җиһазны Кире кайтару акты буенча комплектлы итеп кайтарырга бурычлы.

2.2.9. Әлеге Килешүгә карата булган барлык үзгәрешләр (мәсәлән, үзенең яшәү урыны, пациентның яшәү урыны, паспорт белешмәләре һәм башкалар) турында Медицина оешмасына үзгәрешләр кертелгәннән соң өч көн эчендә язмача хәбәр итәргә бурычлы.

**3. Конфиденциальлек**

3.1. Килешү буенча һәр якның эшчәнлеге турында һәм Килешү буенча алар белән бәйле теләсә кайсы башка шәхеснең эшчәнлеге турында мәгълүмат конфиденциаль булып тора.

**4. Якларның Җаваплылыгы**

4.1. Әлеге Килешү буенча бурычларны үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары белән билгеләнгән җаваплылыкны тоталар.

4.2. Яклар әлеге Килешү буенча бурычларны өлешчә яки тулысынча үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителәләр, әгәр бу хәл әлеге Килешү төзегәннән соң яклар алдан күрә алмый яисә булдырмый кала алмаган гадәттән тыш характердагы хәлләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән үтә алмаслык көчтәге хәлләр барлыкка килү сәбәпле килеп чыккан булса.

4.3. Әлеге Килешү тексты буенча хәл ителеше булмаган мәсьәләләр буенча Яклар арасында килеп чыгарга мөмкин булган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнар нигезендә сөйләшүләр юлы белән хәл ителәчәк.

4.4. Бәхәсле мәсьәләләр сөйләшүләр барышында җайга салынмаган очракта, бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

**5.Йомгаклау нигезләмәләре**

5.1. Әлеге Килешү аңа кул куелган вакыттан башлап үз көченә керә һәм Килешү буенча Яклар тарафыннан үз бурычларын тулысынча үтәп чыгуга кадәр гамәлдә була.

5.2. Килешү Якларның язма килешүе буенча үзгәртелергә яки өзелергә мөмкин.

5.3. Медицина оешмасы Җиһаздан файдалану срогы чыкканчы Килешүне өзүне таләп итәргә хокуклы (1.4 пункт. Шартнамәләр) түбәндәге очракларда:

1) Килешү шартларын бозып Җиһаздан файдалану очрагында яки аның билгеләнеше буенча файдаланмаса;

2) Җиһазга зыян китерелсә;

3) Җиһазны эксплуатацияләү инструкциясен һәм Кагыйдәләрен бозып Җиһаздан файдалану очрагында;

4) Әлеге Килешүне төзү өчен нигез булган шартлар үзгәргән яисә Гражданин тарафыннан килешү буенча кабул ителгән йөкләмәләрне үтәмәгән очракта.

5.4. Барлык белдерүләр һәм хәбәрләр язма рәвештә җибәрелергә тиешләр.

5.5. Әлеге Килешүдә каралмаган башка мәсьәләләр буенча Яклар гамәлдәге законнарга таянып эш итәләр.

5.6. Кушымталар:

№1 Кушымта. Өйдә медицина җиһазыннан файдалану өчен кирәкле булган медицина җиһазы, аңа кирәк-яраклар, медицина билгеләнешендәге предметлар Исемлеге.

№2 Кушымта. Җиһазны Кабул итү-тапшыру акты.

№3 Кушымта. Җиһазны Кире кайтару акты.

№4 Кушымта. Җиһазның халәтен, эффектив һәм максатчан кулланылышын контрольдә тоту кагыйдәләре.

**6. Якларның реквизитлары һәм имзалары**

**Медицина оешмасы**

______________________________________________________________

атамасы

Юридик адрес:______________________________________________

ИНН ____________________

Баш табиб ________________/_____________________
имза расшифровка подписи

**Гражданин**

_______________________________________________________________________________
фамилия, инициаллар
___

Паспорт:_______________ бирү датасы:____________________________________
Бирү органы: _____________________________________________________
Яшәү урынының адресы:______________________________________________
Контакт телефоны: _________________________________________________
Имза:_______________ Дата: ______________________

_______________________________________________________________________________
фамилия, инициаллар

Паспорт:_______________ бирү датасы:____________________________________
Бирү органы: _____________________________________________________
Яшәү урынының адресы:______________________________________________
Контакт телефоны:__________________________________________________
Имза:_______________ Дата: ______________________

20 ___ ел. ______________ № _____
өйдә медицина җиһазлар түләүсез
вакытлы куллануга тапшыру
турында килешүгә
№1 Кушымта

Өйдә файдалану өчен кирәкле медицина җиһазларының, аның әсбәпларының, медицина билгеләнешендәге предметларының Исемлеге

1.
2.
3.

Якларның имзалары

Медицина оешмасы
Баш табибы____________________/________________________________________________
имза                    имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

Гражданин
______________________/_________________________________________________
имза                    имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

______________________/_________________________________________________
имза                    имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

20 ___ ел. ______________ № _____
өйдә медицина җиһазлар түләүсез
вакытлы куллануга тапшыру
турында килешүгә
№2 Кушымта

**Җиһазны Кабул итү-тапшыру акты**

20___ел. «______» _____________.

_____________________
төзү урыны

Бер яктан, устав нигезендә гамәлдә булучы, алга таба «Медицина оешмасы» дип аталучы, ________________________________________________,
медицина оешмасының атамасы

баш табиб йөзендә ________________________________________________ ,

һәм икенче яктан алга таба «Гражданин» дип аталучы ________________________________
махсус медицина җиһазын куллану белән өйдә паллиатив

________________________________________________
медицина ярдәмен күрсәтүгә мохтаж булган пациентны турыдан-туры карауны гамәлгә ашырачак затларның (затның) фамилиясе,

________________________________________________
исеме, атасының исеме

бергә «Яклар» дип аталучы, түбәндәге турында әлеге Актны төзеделәр (алга таба – Акт):

1.Әлеге Акт буенча медицина оешмасы Гражданинга тапшыра, ә Граждан файдалану өчен кирәкле түбәндәге җиһазны, аңа әсбәпларны, медицина билгеләнешендәге предметларны (алга таба – Җиһаз) кабул итә:

| № п/п | Исем | Инвентарь номеры | Серия номеры | Сан | Бәясе, сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |
| 4. | | | | | |
| Итого: | | | | | |

Җиһазны кабул итү-тапшыру акты буенча бөтен Җиһазга бәйләнеше булучы техник паспортларның, эксплуатация буенча инструкциянең копияләре белән.

2.Әлеге актның 1 пунктында күрсәтелгән Җиһаз комплектланган һәм төзек хәлдә. Якларның бер-берсенә карата дәгъвалары юк.

3.Әлеге Акт __(____) нөсхәдә төзелгән, берсе Медицина оешмасы өчен, башкасы(лары) – Гражданин өчен.

Якларның имзалары

Медицина оешмасы
Баш табиб______________________/________________________________________
имза                    имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

Гражданин
______________________/________________________________________
имза                    имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)
______________________/________________________________________

имза                                             имза расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

20 ___ ел. _____________ № ____
өйдә медицина җиһазлар түләүсез
вакытлы куллануга тапшыру
турында килешүгә
№3 Кушымта

**Җиһазны кире кайтару акты**

____________________ 20___ел. «______» ____________.

төзү урыны

Бер яктан, устав нигезендә гамәлдә булучы, алга таба «Медицина оешмасы» дип аталучы, ______________________________________________________________________________,

медицина оешмасының атамасы

баш табиб йөзендә ____________________________________________________________ ,

һәм икенче яктан алга таба «Гражданин» дип аталучы ______________________________

махсус медицина җиһазын куллану белән өйдә паллиатив

______________________________________________________________________________

медицина ярдәмен күрсәтүгә мохтаж булган пациентны турыдан-туры карауны гамәлгә ашырачак затларның (затның) фамилиясе,

______________________________________________________________________________

исеме, атасының исеме

бергә «Яклар» дип аталучы, түбәндәге турында әлеге Җиһазны кире кайтару турында актны төзеделәр (алга таба – Акт):

1.Әлеге Акт буенча Гражданин медицина оешмасына тапшыра, ә Медицина оешмасы түбәндәге җиһазны, аңа әсбәпларны (алга таба – Җиһаз) кабул итә:

| № п/п | Исем | Инвентарь номеры | Серия номеры | Сан | Бәясе, сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |
| 4. | | | | | |
| Итого: | | | | | |

2.Әлеге актның 1 пунктында күрсәтелгән Җиһаз комплектланган һәм төзек хәлдә. Якларның бер-берсенә карата дәгъвалары юк.

3.Әлеге Акт 2 (ике) нөсхәдә төзелгән, берсе Медицина оешмасында, башкасы (лары) – Гражданнарда.

Якларның имзалары

Медицина оешмасы
Баш табиб______________________/__________________________________________________
имза                                             имза расшифровкасы (фамилия, инициал)

Гражданин
______________________/__________________________________________________
имза                                             имза расшифровкасы (фамилия, инициал)
______________________/__________________________________________________
имза                                             имза расшифровкасы (фамилия, инициал)

20 ___ ел. _____________ № _____
Өйдә түләүсез вакытлы куллануга
медицина җиһазын тапшыру
турында килешүгә
№4 Кушымта

**Җиһазның халәтен, нәтиҗәле һәм максатчан кулланылышын тикшерү кагыйдәләре**

1. Медицина оешмасы Җиһазның комплектлыгын һәм төзеклеген даими тикшереп тору хокукын үзендә калдыра.

2. Комплектлыкны һәм төзеклекне тикшерү пациент (законлы вәкил) яисә караучы зат барында Медицина оешмасының вәкаләтле вәкилләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Тикшерү көне турында пациент (законлы вәкил) яки караучы зат алдан ук кисәтелә, ләкин тикшерү көненә кадәр ике тәүлектән дә соңга калмыйча.

4. Җиһазның төзек булмавы ачыкланган очракта пациент (законлы вәкил) яки караучы зат бу хакта Медицина оешмасын кичекмәстән кисәтергә тиеш. Каршы очракта бәхәс барлыкка килгәндә алар әлеге хәлләргә сылтама ясарга хокуклы түгел.

5. Медицина оешмасының вәкаләтле вәкиле, җиһазның төзек булмавы һәм (яки) комплектлы булмавын ачыклаган очракта, ачыкланган җитешсезлекләрне күрсәтеп, ике яклы акт төзи. Югарыда телгә алынган акт, бер яктан, медицина оешмасының вәкаләтле вәкиле, икенче яктан, пациент (законлы вәкил) яки караучы зат тарафыннан имзалана.

Якларның имзалары

Медицина оешмасы
Баш табиб_____________________/_______________________________________________
имза — имзаның расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

Гражданин

_____________________/_______________________________________________
имза — имзаның расшифровкасы (фамилия, инициаллар)

_____________________/_______________________________________________
имза — имзаның расшифровкасы (фамилия, инициаллар)